**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№13** **Әбсәләм авылы** **16 декабрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының
2018 елның 5 июлендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә турында»гы 14 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Ютазы районы прокуратурасы протестын карап, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 июлендәге 14 санлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гавами тыңлаулар турында мәгълүмат бирү» 6 маддәнең 1 бүлегендәге 1.1 пунктчасын:

1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм(яки) бүтән мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында басылып чыга (халыкка җиткерелә).»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: http://jutaza.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларына куярга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева